# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Мичәнбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

28.03.2024 №1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Мичәнбаш авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 26 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып 2024 елның 28 мартында узган гражданнар җыенында «Сез «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Мичәнбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 21.11.2023 ел №1 карарына үзгәрешләр кертүгә « 2024 нче елда Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Мичәнбаш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз ) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге максатларда файдаланырга:

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичәнбаш торак пунктында балалар мәйданчыгы төзү, төзекләндерү дигән сорау буенча 2023 елның 21 нче ноябендә узган халык җыены 1 карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эш төрләренә үзгәртергә:
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Мичанбаш торак пунктында балалар мәйданчыгы төзү) ризамы» дигән сорау буенча 2024 елның 28 мартында узган халык җыены нәтиҗәләре буенча җыен беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган <u>116</u> кеше кертелгән, җыенда һәм тавыш бирүдә катнашучылар саны <u>64</u> кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан <u>64</u> кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы <u>0</u> тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Мичәнбаш торак пунктында халык җыенын үткән дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «Сез «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Мичәнбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 21.11.2023 ел №1 карарына үзгәрешләр кертүгә, 21.11.2023 елгы 1 нче карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эш төрләренә үзгәртүгә:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Мичанбаш торак пунктында балалар мәйданчыгы төзү) ризамы» карарын кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shtmordan адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Шәмәрдән авыл
җирлеге башлыгы А.К.Вәлиев